ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**“Татарстан Республикасында янгыннан ирекле саклау турында” Татарстан Республикасы Законының 4 һәм 11 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2017 елның 11 июлендә
кабул ителде

**1 статья**

“Татарстан Республикасында янгыннан ирекле саклау турында” 2011 елның 1 августындагы 48-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2011, № 8 (I өлеш); 2014, № 5) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяда:

а) исемендә “янгыннан саклау буенча” сүзләреннән соң “ирекле янгын сүндерүчеләр, янгыннан ирекле саклау хезмәткәрләре,” сүзләрен өстәргә;

б) “ирекле янгын сүндерүчеләрнең” сүзләреннән соң “, янгыннан ирекле саклау хезмәткәрләренең” сүзләрен, “ирекле янгын сүндерүчеләрне” сүзләреннән соң “, янгыннан ирекле саклау хезмәткәрләрен” сүзләрен өстәргә;

2) 11 статьяның 1 өлешендә “территориаль” сүзен төшереп калдырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан,Кремль
2017 ел, 20 июль
№ 58-ТРЗ